**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**06.07.2021 ел** **№ 587**

**Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2021 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексы, 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законы, Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күләмнәрен билгеләү методикасы, Биектау муниципаль районы башкарма комитетының «Биектау муниципаль районындагы социаль наем шартнамәсе буенча торак урын мәйданының исәп нормасы һәм торак урын мәйданын бирү нормасы турында» 2021 елның 20 апрелендәге 75 номерлы карары, «Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр берлеге» НПнең 2021 елның 01 февралендәге 26 номерлы «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» бәяләве нигезендә, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2021 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының түбәндәге максималь күләмнәрен билгеләргә:

1.1. Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керем күләменең максималь күрсәткече: 24 758,17 сум;

1.2. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме:

1.1.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен - 736 747,2 сум;
1.1.2. Ике кешедән торган гаилә өчен - 1 473 494,4 сум;
1.1.3. Өч кешедән торган гаилә өчен - 2 210 241,6 сум;
1.1.4. Дүрт кешедән торган гаилә өчен - 2 946 988,8 сум;
1.1.5. Биш кешедән торган гаилә өчен - 3 683 736 сум;
1.1.6. Алты кешедән торган гаилә өчен - 4 420 483,2 сум;
1.1.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен - 5 157 230,4 сум;

1.2. Гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык керем күләме:
1.2.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен - 24 758,17 сум;
1.2.2. Ике кешедән торган гаилә өчен - 24 758,17 сум;
1.2.3. Ике кешедән торган гаилә өчен - 24 758,17 сум.

2. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлегенә әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән чик күрсәткечләрне гражданнарны аз керемлеләр дип тану өчен исәпкә кую һәм социаль наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондының торак урыннарын аларга бирү максатларында кулланырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) халыкка җиткерергә һәм Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Р.Ф. Хәкимуллинга йөкләргә.

Биектау муниципаль районы башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Р.Р. Сабирҗанов

Кушымта
Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы Башкарма комитетының
2021 елның «06» июлендәге 587 номерлы
карарына

**Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2021 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү**
**МЕТОДИКАСЫ**

1. Муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү нормасы буенча торак урыннары алу өчен базар хакының исәпләнгән күрсәткече (алга таба-исәп-хисап күрсәткече) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

СЖ = НП х РС х РЦ,

монда:

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү нормасы буенча торак урын сатып алуның базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече;

НП - әлеге муниципаль берәмлектә гаиләнең бер әгъзасына торак урын бирү нормасы;

РС - гаилә әгъзалары саны;

РЦ -әлеге муниципаль берәмлекнең уртача шартларына һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин ителешкә туры килә торган торак урын мәйданының бер квадрат метрының Татарстан Республикасында торак урын сатып алуга түләүсез субсидияләр исәпләү өчен тиешле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән гомуми мәйданның бер квадрат метрының уртача базар бәясеннән артмый торган уртача исәпләнгән базар бәясе.

«Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 2021 елның 01 февралендәге 26 номерлы «Татарстан Республикасының Бәяләүчеләр берлеге» НП хаты нигезендә Биектау муниципаль районы буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе 2021 елга 40 930,4 сум тәшкил итә.

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:
СЖ = 40 930,4 х 18 = 736 747,2 сум
б) ике кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 40 930,4 х 18 х 2 = 1 473 494,4 сум
в) өч кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 40 930,4 х 18 х 3 = 2 210 241,6 сум
г) дүрт кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 40 930,4 х 18 х 4 = 2 946 988,8 сум
д) биш кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 40 930,4 х 18 х 5 = 3 683 736 сум
е) алты кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 40 930,4 х 18 х 6 = 4 420 483,2 сум
ж) җиде кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 40 930,4 х 18 х 7 = 5 157 230,4 сум
3) сигез кешедән торган гаиләгә:
СЖ = 40 930,4 х 18 х 8 = 5 893,977,6 сум

2. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме СЖ хисап күрсәткеченә тигез итеп кабул ителә.

Граждан гаиләсенең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме түбәндәгечә билгеләнә:

1) торак урын сатып алуга ипотека кредиты алу мөмкинлеге булган шәһәрләрдә – түбәндәге формула буенча билгеләнә торган СЖ исәпләү хакы буенча торак урын сатып алуга агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем дәрәҗәсеннән чыгып:

**ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1 - (1 + ПС) $^{-КП}$ ) / (0,25 х РС),**

монда:

ПД - гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган һәм СЖ исәп-хисап бәясе буенча торак урыны алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керемнең максималь күрсәткече;

СЖ –исәп-хисап күрсәткече;

ПС - кредит буенча айлык процент ставкасы (унарлы вакланма), (коммерциячел кредит оешмаларының ачык чыганакларыннан мәгълүмат буенча) елга 12 %, ягъни айга 12/12/100 = айга 0,01);

КП - бөтен кредит срогына кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны);

РС - гаилә әгъзаларының саны;

0,7 - кредит суммасы һәм фатир бәясе нисбәте;

0,25 - кредит буенча түләүнең гаилә айлык җыелма кереме белән чагыштырмасы;

Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга<br>туры килә торган керемнең максималь күрсәткече<br>исәбе

1 нче табл.

| НП - торак урыны нормасы (кв. м) | СЖ - торак бинаны сатып алуның базар бәясе (СЖ = РС х РЦ х НП) (руб.) | РС - гаилә әгъзалары саны (кеше) | РЦ - 1 кв. м торак бинаның базар бәясе (сум) | ПС - кредит буенча айлык процент ставкасы, % | КП - кредит буенча түләүләр нең гомуми саны (ай) | Кредит суммасы һәм фатир бәясенең нисбәте | Кредит буенча түләүнең айлык җыелма керем белән нисбәте | Керемнең максималь кыйммәте (сум) (1 кешегә) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | |
| | | | 40 930,4 | 12/12/100= 0,01 | 180 | 0,7 | 0,25 | |
| 18 | 736 747,2 | 1 | 40 930,4 | 0,01 | 180 | 0,7 | 0,25 | 24 758,17 |
| 36 | 1 473 494,4 | 2 | 40 930,4 | 0,01 | 180 | 0,7 | 0,50 | 24 758,17 |
| 54 | 2 210 241,6 | 3 | 40 930,4 | 0,01 | 180 | 0,7 | 0,75 | 24 758,17 |
| 72 | 2 946 988,8 | 4 | 40 930,4 | 0,01 | 180 | 0,7 | 1,00 | 24 758,17 |
| 90 | 3 683 736 | 5 | 40 930,4 | 0,01 | 180 | 0,7 | 1,25 | 24 758,17 |
| 108 | 4 420 483,2 | 6 | 40 930,4 | 0,01 | 180 | 0,7 | 1,50 | 24 758,17 |
| 126 | 5 157 230,4 | 7 | 40 930,4 | 0,01 | 180 | 0,7 | 1,75 | 24 758,17 |
| 144 | 5 893,977,6 | 8 | 40 930,4 | 0,01 | 180 | 0,7 | 2,00 | 24 758,17 |

Гражданның һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган айлык уртача җыелма керемнең максималь күләмен исәпләү

1. Ялгыз яшәүче кешегә:
ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1- (1 + ПС)$^{-кп}$) / (0,25 х РС) = 0,7 х 736 747,2х0,01 / (1 -1/1,01$^{180}$) / (0,25 х 1) = 5 157,23/1-0,16678/0,25 = 5 157,23/0,8332166/0,25 = 24 758,17

2. Ике кешедән торган гаиләгә:
ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1- (1 + ПС)$^{-кп}$) / (0,25 х РС) = 0,7 х 1 473 494,4х0,01 / (1 -1/1,01$^{180}$) / (0,25 х 2) = 10 314,46/1-0,16678/0,5 = 10 314,46/0,8332166/0,5= 24 758,17

3. Өч һәм аннан күбрәк кешедән торган гаиләгә:
ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1- (1 + ПС)$^{-кп}$) / (0,25 х РС) = 0,7 х 2 210 241,6 х0,01 / (1 -1/1,01$^{180}$) / (0,25 х 3) = 15 471,69/1-0,16678/0,75 = 15 471,69/0,8332166/0,75= 24 758,17